ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО ГСЖГ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА 1 БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН КЯм | РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«16 »июль 2019 ел

**КАРАР**
№ 169

**Балтач муниципаль районы башлыгы призына Балтач муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары арасында 2019 ел уңышын җыеп алу буенча районкүләм ярыш үткәрү турында**

Ашлык җитештерү күләмен арттыру, урып-җыю эшләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару һәм комбайнчыларны 2019 елгы уңышын җыеп алуга матди кызыксындыру максатларында, Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Балтач муниципаль районы башлыгы призына Балтач муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары арасында 2019 елгы бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыеп алу буенча район ярышы үткәрергә.
2. Балтач муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары арасында 2019 елгы бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыюда ярышлар үткәрү турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.
3. 2019 елгы бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыюда Балтач муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре шоферларын, комбайнчыларны өстәмә бүләкләү турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
4. Ярыш белән гомуми җитәкчелекне тәэмин итү һәм ярышларга йомгак ясау өчен, кушымта нигезендә комиссия составын расларга (3 нче кушымта).
5. Ярышларга йомгак ясау максатыннан, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә, көндәлек мәгълүматне Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балтач районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тапшыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
6. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына җирле бюджеттан финанс чыгымнарны бүлеп бирүне тәэмин итәргә.
7. Район ярышлары нәтиҗәләрен Балтач муниципаль районының «Хезмәт» газетасында һәм рәсми сайтында урнаштырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары Н.Н. Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин

16.07.2019 елгы №169
Балтач муниципаль районы
башлыгы карарына 1 нче
кушымта

**Балтач муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары арасында 2019 елгы бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыюда ярышлар үткәрү турындагы нигезләмә**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

Комбайнчылар арасындагы ярышларның төп максаты - ашлык җитештерү күләмнәрен арттыру, бөртекле һәм кузаклы культураларны сыйфатлы һәм агротехник срокларда җыеп алу.

## 2. Ярышларны оештыру һәм үткәрү тәртибе

Комбайнчылар арасындагы ярышларда җиңүче комбайн шартлы берәмлеге өчен иң югары ашлык суктыру буенча билгеләнә (тоннада) *.

Конкурсны уздыру вакыты: 2019 елның 6 августыннан 16 сентябренә кадәр.

Ярышларга йомгак урып-җыю эшләре тәмамланганчы һәр җиде көн саен ясала.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

## 3. Ярышларда җиңүчеләрне бүләкләү

Атна саен алдынгы комбайнчы 2000 (ике мең) сум күләмендә акчалата премия һәм район башлыгының «2019 елның иң яхшы комбайнчы» вымпелы белән бүләкләнә.

*Комбайннарны физик берәмлекләрдән шартлы берәмлекләргә күчерү коэффициентлары: Джондир \^-540 - 1,1; Тукано - 430 - 1,2; Полесье КЗС-1218 - 1,4; Акрос-550 - 1,19; Акрос- 530 - 1,1; Дон-1500 - 1,0; Полесье КЗС-812 - 0,9; Енисей КЗС-950 - 0,8; Полесье КЗС-7 - 0,76; Енисей-1200 - 0,7; СК-5 «Нива» - 0,6.

16.07.2019 елгы №169
Балтач муниципаль районы
башлыгы карарына 2 нче
кушымта

Балтач районында 2019 елгы бөртекле һәм кузаклы культураларны урып-җыюда эшләүче комбайнчыларны, машина йөртүчеләрне өстәмә бүләкләү турында нигезләмә

| Комбайннар | Саны, бер. | Бер комбайнга беренче ашлык суктыру, тн | Беренче суктыру өчен премия, сум | Бер комбайнга икенче ашлык суктыру, тн | Икенче суктыру өчен премия, сум | Бер комбайнга өченче ашлык суктыру, тн | Өченче суктыру өчен премия, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Джондир W-540 | 1 | 550 | 500 | 550 | 1000 | 550 | 1500 |
| Тукано 430 | 2 | 600 | 500 | 600 | 1000 | 600 | 1500 |
| Полесье КЗС- 1218 | 4 | 700 | 500 | 700 | 1000 | 700 | 1500 |
| Акрос-550 | 7 | 595 | 500 | 595 | 1000 | 595 | 1500 |
| Акрос-530 | 3 | 550 | 500 | 550 | 1000 | 550 | 1500 |
| Дон-1500 | 20 | 500 | 500 | 500 | 1000 | 500 | 1500 |
| Полесье КЗС-812 | 17 | 450 | 500 | 450 | 1000 | 450 | 1500 |
| Полесье КЗС-7 | 9 | 380 | 500 | 380 | 1000 | 380 | 1500 |
| Енисей КЗС-950 | 1 | 400 | 500 | 400 | 1000 | 400 | 1500 |
| СК-5 "Нива" | 25 | 300 | 500 | 300 | 1000 | 300 | 1500 |

Комбайннан ындыр табагына кадәр ашлык ташуда эшләүче алдынгы машина йөртүчеләр урып җыю азагында ЮООәр сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә (тн.км саны буенча иң зур күрсәткеч өчен (1әр машина йөртүчегә: КамАЗ, ЗИЛ, ГАЗ-53)

16.07.2019 елгы №169
Балтач муниципаль районы
башлыгы карарына 3 нче
кушымта

**Балтач муниципаль районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчылары арасында 2019 елгы бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыюда ярышлар үткәрү буенча комиссия составы**

Сабирҗанов Н..Н. - район башлыгы урынбасары - комиссия рәисе

Галимов И. Ф. - Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Анваров И. З. - Балтач муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Гатиятуллин Ф. Р. - Балтач муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге консультанты (килешү буенча)

Нуриев Р. М. - Балтач муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча)

Әхмәдиев Э. Р. - Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча)